ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ СӘФӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423748, Иске Сэфэр авылы,
М.Вахитов ур., 16 нчы йорт.
Тел.5-60-43

СОВЕТ СТАРОСАФАРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423748, село Старое Сафарово,
ул. М.Вахитова ,дом 16 , Тел. 5-60-43

**КАРАР**
**17 .09.2019 ел**

**Решение**
**_22_**

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

12.06.2002 ел,№ 67-ФЗ "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 15 статьясы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12, 17 статьялары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Иске Сәфәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге Советы

**Карар чыгарды:**

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне инициировать итергә:

"2020 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, аларның җирле референдумда катнашуына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, аларның саны җирлек халкының гомуми санынннан 30 проценттан да артмый, алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында:

Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Иске Сәфәр, Иске Кадырмәт, Терпельдә урам юлларын ремонтлау һәм карап тоту;
- Иске Сәфәр авылында Терпеле елгасы аша җәяүлеләр өчен салынган басманы ремонтлау;

Җирлек чикләрендә Халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су чыгару, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:

- скважиналарны лицензияләү Иске Сәфәр, Иске Кадырмәт, Терпельдә су челтәрләрен карап тоту һәм алыштыру;;

Авыл җирлегендә яшәүчеләрнең массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру

- Иске Кадырмәт һәм Терпеле авылларындагы һәйкәлне ремонтлау;;

Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:

- зират коймасын буяу өчен лак-буяу материаллары сатып алу;

Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- җирлек торак пунктларында урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр урнаштыру;

"ӘЙЕ "                                        "ЮК"

2. Әлеге карар махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган: ТР, Актаныш муниципаль районы, Иске Сәфәр авылы, М.Вахитов ур., 16 йорт, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы                                        Г.З.Сайфутдинова